**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№11009**
**13.11.2023**

Башкарма комитетның 2022 елның 21 февралендәге 818 номерлы Карары белән расланган Россия Федерациясе Архив фонды һәм башка архив документлары нигезендә физик һәм юридик затларны мәгълүмат белән тәэмин итү, архив белешмәләрен, архив өземтәләрен һәм архив документларының күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 21 февралендәге 818 номерлы Карары белән расланган Россия Федерациясе Архив фонды һәм башка архив документлары нигезендә физик һәм юридик затларны мәгълүмат белән тәэмин итү, архив белешмәләрен, архив өземтәләрен һәм архив документларының күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 2.5.2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2) шифрлы (криптографик) чаралардан файдаланып сакланган каналлар, мәгълүмат-телекоммуникация системалары һәм элемтә челтәрләре буенча турыдан-туры Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды бүлекчәләренә һәм, алар һәм архив эше өлкәсендә башкарма хакимиятнең тиешле органы яки җирле үзидарә органы арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзү шарты белән, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр аша;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан

Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев